Контрольно - измерительные материалы
для проведения промежуточной аттестации
(тестирование)
по родному языку (татарскому)
(для изучающих татарский язык как родной)
8 класс

Спецификация

Контрольно – измерительные материалы предназначены для проведения процедуры промежуточной аттестации учащихся 8 класса по учебному предмету « Родной язык (татарский)».

Контрольно-измерительные материалы составлены на основе Федерального компонента государственного образовательного стандарта основного общего образования, в соответствии с действующей рабочей программой по учебному предмету «Родной язык (татарский)».

Цель: оценка общеобразовательной подготовки обучающихся по родному языку (татарскому) за курс 8 класса.

Форма проведения промежуточной аттестации – контрольный тест. Итоговая работа по родному языку (татарскому) за курс 8 класса в форме контрольного теста соответствует учебной программе.

Итоговый контрольный тест рассчитан на 45 минут. В ходе его выполнения ученик должен будет продемонстрировать уровень сформированности личностных, предметных и метапредметных результатов.

Предметные результаты

«Лексика»:

- знать лексические единицы, уметь подбирать примеры лексических единиц и давать их точное определение;

«Синтаксис»:

- умение применять правила постановки знаков препинания в конце предложения, в простом и в сложном предложениях; определять вид связи в словосочетаниях, различать односоставные и двусоставные предложения;

«Пунктуация»:

- умение соблюдать пунктуационные нормы в процессе письма;
- умение находить в предложениях смысловые отрезки, которые необходимо выделить знаками препинания,
- обосновывать выбор знаков препинания и расставлять их в соответствии с изученными правилами.

«Орфоэпия. Орфография. Морфология»:
- умение расставлять ударения в словах;
- умение записывать слова, осуществлять самоконтроль в процессе письма, владеть навыками правописания;
- умение находить и исправлять ошибки в образовании формы слова.

Личностные результаты:
- готовность и способность обучающихся к саморазвитию и самообразованию на основе мотивации к обучению и познанию;
- сформированность ответственного отношения к учению; уважительного отношения к труду, наличие опыта участия в социально значимом труде;
- сформированность целостного мировоззрения, соответствующего современному уровню развития науки и общественной практики, учитывающего социальное, культурное, языковое, духовное многообразие современного мира.

Метапредметные результаты:
- способность и готовность ученика к освоению знаний, их самостоятельному выполнению, переносу и интеграции;
- способность к самоорганизации, саморегуляции и самоконтролю в процессе письма;
- умение находить, в том числе из предложенных вариантов, условия для выполнения учебной и познавательной задачи;
-умение находить в тексте требуемую информацию (в соответствии с целями своей деятельности).

Структура КИМ

Тест состоит из 2 частей: часть 1 включает 12 заданий с выбором ответа либо с записыванием краткого ответа; часть 2 состоит из заданий работы с текстом.

Кодификатор контрольно - измерительных материалов.

№	Содержание проверочных заданий	Планируемые результаты	Максимал. балл
А1	Синтаксис. Сочинительная связь	**предметные:** проверить полученные знания и умения **коммуникативные:** умение размышлять и формулировать	1
А2	Синтаксис. Тип словосочетания		1
А3	Средство связи в словосочетании		1

А4	Синтаксис. Простое предложение	**регулятивные:** умение достигать поставленной цели **познавательные:** использование приобретенных знаний **личностные:** понимание своих возможностей	1
А5	Главные члены предложения		1
А6	Главные члены предложения		1
А7	Второстепенные члены предложения. Определение		1
А8	Второстепенные члены предложения. Обстоятельство		1
А9	Второстепенные члены предложения. Обстоятельство		1
А10	Однородные члены предложения		1
А11	Обращение		1
А12	Односотавное предложение		1
В13	Главные члены предложения		2
В14	Однородные члены предложения		2
В15	Нераспространенное предложение		2
В16	Порядок слов в предложении		2
В17	Простое предложение		2

Критерии оценивания:

Балл	20-22 балл	16-19 балл	12 -15 балл	0- 11 балл
%	90-100 %	70-89%	45 -6 9%	20-44%
Билге	“5”	“4”	“3”	“2”

Тест

I вариант

1 нче өлеше (А)

А1. Тезүле бәйләнешкә кергән сүзләрне табыгыз.
1) урманга хәтле бару;
2) һәвәскәр композитор;
3) сөенечле, шатлыклы, ләззәтле
4) кызлар, бигрәк тә Галия белән Алсу

А2. Исем сүзтезмәне табыгыз.
1) барасы урын;
2)икегә аерылып;
3) хат язарга ашыгу;
4) авыл аркылы үтү.

А3. *Матурлыкны күрү, кошларның сайравы* сүзтезмәләрендә бәйләүче чара:
1) янәшәлек;
2) сүзләрне кабатлау;
3) сүз тәртибе;
4) килеш кушымчасы.

А4. *Бүген Алсуларга керәсе түгел!* җөмләсе — ...
1) раслау җөмлә;
2) инкяр җөмлә;
3) кушма җөмлә;
4) сорау җөмлә.

А5. Хәбәрлекнең санын билгеләгез.
Кемнәрнеңдер каләме сынды, берәүнең карасы түгелде, кемнеңдер чалбары буялды.
1) бер;
2) ике;
3) өч;
4) дүрт.

А6. *Тереклек чыганагы - кояш – табигатькә әнә шулай җан кертте* җөмләсендә ия булып килә :
1) тереклек сүзе;
2) чыганагы сүзе;
3) кояш сүзе;
4) җан сүзе килә.

А7. *Яз көне каен агачындагы <u>иң шифалы</u> матдәләр аның яфракларында, бөреләрендә тупланган.* (Ф.Ә.) җөмләсендә астына сызылган сүзнең җөмлә кисәге буларак функциясен билгеләгез.

1) ия;
2) аергыч;
3) тәмамлык;
4) хәл.

А8. *<u>Иртән</u> торуга иң беренче куанычым шул: ипи йомшагы эләктерәм дә колын янына чабам* җөмләсендә билгеләнгән хәлнең төркемчәсен билгеләгез.

1) вакыт хәле;
2) күләм хәле;
3) урын хәле;
4) рәвеш хәле.

А9. *Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп* (Г.Тукай) җөмләсендә *утынга* сүзе ...
1) туры тәмамлык;
2) кыек тәмамлык;
3) максат хәле;
4) сәбәп хәле булып килә.

А10. Җөмләдә тиңдәш кисәкләрне табыгыз, төрен билгеләгез. *Өй түбәләрендә, коймаларда, агач башларында – бөтен җирдә бәс.*

1) тиңдәш хәбәр;
2) тиңдәш ия;
3) тиңдәш тәмамлык;
4) тиңдәш хәл.

А11. Эндәш сүзе булган җөмләне күрсәтегез.

1) И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә – эш.

2) Яз җитү белән, җирдә тереклек җанлана.

3) 1Чияле тау янынан зифа ак каеннар, төз наратлар үскән зур куе урман башлана.

4) Егетләр, сафка тезелмичә генә, алда көткән ялга, тыныч йокыга өметләнеп, вагоннарына юнәлделәр.

А12. Бер составлы җөмләне күрсәтегез.

1) Матур кояш, иртә белән кызарып, күк йөзенә күтәрелде.

2) Җәйгә дә ерак калмады.

3) Җәяүле дә, атлы да юлга чыгарлык түгел.

4) Яшел хәтфә келәм өстенә утырып, бераз тамак ялгап алгач, без күл буена юнәлдек.

2нче өлеше (В)

Текстны укыгыз һәм В1-В6 биремнәрне текст нигезендә үтәгез. Җавапларны сүз яки саннар белән языгыз.

1)Табигатьтә яз билгеләре күренә башлады. 2) Кыш буена җирнең өстен каплап яткан юка кар тиз арада юкка чыкты. 3) Өй түрендәге миләш ботаклары да яшелрәк төскә керделәр. 4)Түбә читләрендә боз сөңгеләре күренде. 5) Елгалардан, инешләрдән генә түгел, тар үзәннәрдән дә шаулап, күбекләнеп, бозлы сулар акты. 6) Менә яз хәбәрчеләре – кара каргалар – килеп, су буендагы биек талларга, тирәк башларына оя кордылар.

7) Кояш хәзер җиргә турырак карый, ышык җирләрдә сизелерлек җылытты. 8)Тереклек чыганагы – кояш – табигатькә әнә шулай җан кертте. 9)Чәчкечләр, сабан, тырмалар барланды, амбарлар ачылды.

10)Сабан тургайлары, язгы табигатькә иртәнге сәламнәрен җиткерү өчен, зәңгәр күккә күтәреләләр. 11) Язны мактап, озак-озак сайрый алар. 12) Көн буена кошлар тавышы тынып тормый.

В13. 3нче җөмләнең грамматик нигезен язып алыгыз.

В14. Тиңдәш кисәкләре булган җөмләләрнең номерларын күрсәтегез

В15. Җыйнак җөмләнең номерын күрсәтегез.

В16. Кире сүз тәртибе булган җөмләнең номерын күрсәтегез.

В17. 10-12 нче җөмләләрдән инкарь җөмләнең номерын күрсәтегез.

Дөрес җаваплар

№	Җаваплар
A1	2
A2	1
A3	4
A4	2
A5	3
A6	2
A7	2
A8	1
A9	3
A10	4
A11	1
A12	3
B13	миләш ботаклары керделәр
B14	5, 6, 9
B15	9
B16	11
B17	12